**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 декабрь 2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Кече Кариле авылында гражданнарның җыены карар итте**:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** ( шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, грейдирование, юлларны кышкы чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);;

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән язгы-көзге чорда чүп үләннәренчабу, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)** (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын депосын һәм автоцистернаны тоту , ягулык-майлау материаллары, АЦ-40 (131) өчен запас частьләр сатып алу)».

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Гарифуллин